**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«10» ноябрь 2023 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Киекле авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

Киекле авыл җирлегенең Киекле авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан кала, балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, лицензияләү, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм эчәр су белән тәэмин итү максатыннан халыкка су бирүне тәэмин итү;
- Киекле торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту, шул исәптән таш, суккан кирпеч, туфрак, вак таш, ком, асфальт ватыклары (сатып алу, ташу, салу), чокыр ремонты (коелган асфальт);

Киекле торак пунктында урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) төзү, сатып алу;

Киекле торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;
- ремонт, коймалар төзү, Киекле торак пунктында традицион җирләү урыннарын 3 данә күләмендә төзекләндерү;

халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау, товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу һәм Киекле торак пунктында аларга якын территорияне төзекләндерү.

Халык җыенында рәислек итүче: Л.И. Кашапова

Киекле авыл җирлеге башлыгы: Л.И. Кашапова